Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Каклы Күл авылында
**гражданнар җыены карары**

2019 елның 21 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Каклы Күл авылында гражданнар җыены **к**арар кабул итте:

1. 2020 елда, көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Ютазы муниципаль районы Каклы Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым алуны кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Каклы Күл авылында юлларны кардан чистарту;
- Каклы Күл авылында зират ихаталарын алыштыру (сатып алу, килешү буенча эшкә түләү).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга..
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урыссу авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Ф. Г. Әминова